РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИХАЙЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА МИХАЙЛОВКА ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423975 РТ, с. Михайловка. Ул. Гагарина, 24*
*тел. (8-85556) 3-62-32*

---

Михайловка авылы 03.02.2020 ел.

Карар № 4

«Михайловка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Михайловка авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 декабрендәге 18 номерлы Михайловка авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Бюджет кодексының 174.3 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә, Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Михайловка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Михайловка авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 декабрендәге 18 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Әлеге карарга 1 нче кушымтада расланган Михайловка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Михайловка авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү тәртибенең 19 пунктының б) пунктчасындагы 2 абзацын түбәндәге формула белән тулыландырырга:

$$E = \sum_{i=1}^{5} \sum_{j=1}^{m_i} \frac{N_{ij} - B_{oj} \times (1 + g_i)}{(1 + r)^i}.$$

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар закон белән билгеләнгән срокта үз көченә керә.

Михайловка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Х. Исламов